**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2019 № 458

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары хакында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 15 маендагы Пр-817ГС номерлы Россия Федерациясе дәүләт советы утырышы нәтиҗәләре буенча йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары хакында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен расларга (әлеге карарга кушымта).

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны узем артыннан калдырам.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 10 июнендәге
458 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары хакында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары хакындагы мәгълүматны, аны алу белән кызыксынучы затларга файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - Интернет челтәре) бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә муниципаль берәмлекләр милкендәге күчемсез милек объектлары хакындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә бастырып чыгару өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булып tetushi.tatarstan.ru сайты тора.

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастыруга вәкаләтле орган булып Тәтеш муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тора.

4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы, шәһәр һәм авыл җирлекләре милкендә булган муниципаль милек реестрына кертелгән күчемсез милек объектлары хакында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы, шәһәр һәм авыл җирлекләре милкендәге җир участоклары турында мәгълүмат басылып чыгарга тиеш. Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат әлеге тәртипнең 1,2 нче кушымтасы нигезендә, күчемсез милек объектлары турында реестр рәвешендә басылып чыга.

6. Мәгълүмат бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла. Муниципаль милек реестрында теркәлгән аерым милек объектлары буенча мәгълүмат кызыксынган мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль милек реестрыннан өземтә формасында бирелә.

7. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару, бердәм дәүләт реестрындагы күчемсез милек турындагы мәгълүмат, шулай ук Тәтеш муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы күрсәтә торган мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында бастырып чыгарылган мәгълүматны актуальләштерү хисап чорыннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр вәкаләтле орган тарафыннан квартал саен гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы
муниципаль милкендәге күчемсез милек объектлары
турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибенә
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге объектлар реестры

| № | Милек исемлеге | Урнашкан урыны (адресы) | Мәйданы, кв.м | Максатчан билгеләнеше | Чикләүләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибенә
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге җир кишәрлекләре реестры

| № | Милек исемлеге яки кадастр номеры | Урнашкан урыны (адресы) | Мәйданы, кв.м | Җир категориясе | Максатчан билгеләнеше (куллануга рөхсәт) | Чикләүләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |